**Каенсар авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

**2022 елның 22 августы** **№ 22**

Кукмара муниципаль районы Каенсар авыл җирлегенең Каенсар авылында «Кукмара муниципаль районы Каенсар авыл җирлегенең Каенсар авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 26 ноябрендәге 1 номерлы Каенсар авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Каенсар авыл җирлеге Уставының 20 ст. нигезендә Каенсар авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. 2022 елның 2 сентябренә 18 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Каенсар авыл җирлегенең Каенсар авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 26 ноябрендәге 1 номерлы Каенсар авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Каенсар авылы, Һ.Такташ ур., 23 адресы буенча мәдәният йортында үткәрергә

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Кукмара муниципаль районы Каенсар авыл җирлегенең Каенсар авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 26 ноябрендәге 1 номерлы Каенсар авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме:

- 2 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« - Каенсар авылында ике җәяүлеләр күперен урнаштыру, ремонтлау һәм карап тоту»;

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Каенсарк авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Каенсар авыл җирлеге башлыгы урынбасары Г.Г. Рәхмәтуллин